КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июль г.Казань № 554

Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 һәм 6 пунктлары нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы түбәндәгеләр буенча вәкаләтле орган булып тора дип билгеләргә:

түбәндәгеләрне кабул итүне һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыручы:

җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, арендага бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне,

Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның (алга таба – объект), масштаблы инвестицион проектның (алга таба – проект) Татарстан Республикасы Җир кодексы кушымтасында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны,

объектны урнаштыруны яки проектны тормышка ашыруны күздә тота торган

килешүләргә үзгәрешләр кертү турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм мондый үзгәрешләр кертү кирәклеген дәлилли торган документларны;

объектны урнаштыру яки проектны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, арендага бирү турында мәгълүмат булган, шулай ук объект яки проект параметрларына үзгәрешләр кертү турында мөрәҗәгать булган юридик затлар мөрәҗәгатьләренең җыелма реестрын алып бару буенча;

объектның яки проектның Татарстан Республикасы Җир кодексы кушымтасында билгеләнгән критерийларга туры килүе турында, шулай ук объектның яки проектның параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлылыгы турында мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын әзерләү буенча;

объектны урнаштыруны яки проектны тормышка ашыруны күздә тота торган килешү төзү буенча.

3. Объектларны урнаштырганда һәм эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнарын объектның, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексы кушымтасында билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын, шулай ук объект, проект параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлылыгы турындагы мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын килештерү һәм документларны карап тикшерү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен торглар үткәрмичә бирү турындагы Татарстан Республикасы Президенты боерыклары проектларын әзерләү буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә бирү турындагы Татарстан Республикасы Президенты боерыкларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Президенты боерыклары проектларын әзерләү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

үзенең норматив хокукый актларын бу карарга туры китерергә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу карарны тормышка ашыру өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турындагы нигезләмәләргә тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу карар белән расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

7. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы

Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 734 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 август, 608 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче карарындагы 1 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 11 июнь, 455 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилле торган документларны карап тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 февраль, 109 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 ноябрь, 1047 нче карары.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин